МИНИСТЕРСТВО
ЦИФРОВОГО РАЗВИТИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
УПРАВЛЕНИЯ,
ИНФОРМАЦИОННЫХ
ТЕХНОЛОГИЙ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ ИДАРӘСЕН
ЦИФРЛЫ НИГЕЗДӘ
ҮСТЕРҮ, МӘГЪЛҮМАТ
ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 18.11.2024 г. Казань № п/236

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2021 елның 28 сентябрендәге п/255 номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында коррупция куркынычы булган вазифаларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре, шулай ук үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2021 елның 28 сентябрендәге п/255 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре, шулай ук үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлеген раслау хакында» боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат

технологияләре һәм элемтә министрлыгында коррупция куркынычы булган вазифаларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре, шулай ук үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлегенә үзгәрешләр кертү, аны яңа редакциядә тәкъдим итү (кушымта итеп бирелә).

Министр А.Р.Хәйруллин

Татарстан Республикасы дәүләт
идарәсен цифрлы нигездә үстерү,
мәгълүмат технологияләре һәм
элемтә министрлыгының 2021
елның 28 сентябрендәге п/255
номерлы приказы белән расланган
(редакцияләнгән варианты 2024
елның 18 ноябрендәге п/236
номерлы приказы)

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының 2021 елның 28 сентябрендәге п/255 номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгында коррупция куркынычы булган вазифаларны биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре, шулай ук үз хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәткә бәйле йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифалары исемлеге.

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларының «җитәкчеләр» категориясендәге югары төркем вазифалары:

министрның беренче урынбасары;

министр урынбасары, 2 штат берәмлеге.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларының «җитәкчеләр» категориясендәге төп төркем вазифалары:

эшләр белән идарә итүче;

дәүләт идарәсенең цифрлы үсеш бүлеге башлыгы;

тармакны планлаштыру һәм программалаштыру бүлеге башлыгы;

икътисад һәм социаль өлкә тармакларының цифрлы трансформациясен координацияләү бүлеге башлыгы;

мәгълүмат куркынычсызлыгын координацияләү бүлеге башлыгы;

элемтә хезмәтләрен үстерү бүлеге башлыгы;

бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге башлыгы – баш бухгалтер;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы;

хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы;

оештыру эшләре бүлеге җитәкчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларының «җитәкчеләр» категориясендәге әйдәп баручы төркем вазифалары:

ситуацион үзәк эшчәнлеген тәэмин итү секторы мөдире;

икътисади анализ һәм фаразлау секторы мөдире;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү секторы мөдире;

ИТ-бергәлекне үстерү секторы мөдире.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларының «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге әйдәп баручы төркем вазифалары:

министр ярдәмчесе.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларының «белгечләр» категориясендәге әйдәп баручы төркем вазифалары:

дәүләт идарәсенең цифрлы үсеш бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

тармакны планлаштыру һәм программалаштыру бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, 2 штат берәмлеге;

икътисад һәм социаль өлкә тармакларын цифрлы трансформацияләүне координацияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, 2 штат берәмлеге;

мәгълүмат куркынычсызлыгын координацияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

элемтә хезмәтләрен үстерү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

икътисади анализ һәм фаразлау секторының әйдәп баручы киңәшчесе;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

хокукый тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазифаларының «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге әйдәп баручы төркем вазифалары:

режимлы эш һәм махсус элемтә белгече (әйдәп баручы белгеч);

бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлегенең әйдәп баручы белгече, 3 штат берәмлеге;

кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең әйдәп баручы белгече;

тармакны планлаштыру һәм программалаштыру бүлегенең әйдәп баручы белгече, 2 штат берәмлеге;

оештыру эшләре бүлеге белгече, 2 штат берәмлеге;

ИТ-бергәлекне үстерү секторының әйдәп баручы белгече.